| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

2023 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы күләмен раслау турында.

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгы тарафыннан расланган «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр раслау турында» 06.04.2018 ел, № 213/пр боерыгы белән, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131 Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга 6 процент күләмендә күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексын расларга.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә,шулай ук Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/. адресы буенча урнаштырылырга тиеш
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе — Р.А. Файрушин

Утюгина А.А